**СОВЕТ БУРЕВЕСТНИКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423194, с.Слобода Волчья, ул. Центральная, 29

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БУРЕВЕСТНИК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423194, Волчья Бистәсе, Үзәк урамы, 29

тел.: (8-84348) 36-1-31, факс: (8-84348) 36-0-97 эл. почта Burev.Nsm@tatar

КАРАР
Буревестник авыл җирлеге Советы
Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының

2025 елның «30» декабреннән № 4-13

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Буревестник авыл җирлеге Советының 3.11.2023 елның № 39-124 номерлы «җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында»карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законнар, җирле үзидарә турында 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасында, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Буревестник авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы белән, Россия Федерациясе Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Буревестник авыл җирлеге Советы

Карар итте:

1. Карарга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Буревестник авыл җирлеге Советының «җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында 3.11.2023 № 39-124 карарына (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Буревестник авыл җирлеге Советының 11.06.2024 № 46-144 карарлары редакциясендә;) (алга таба-Карар) түбәндәге үзгәрешләр:

1.1. карарның 1 пунктындагы 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1) Россия Федерациясенең Граждан-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат булган яисә вафат дип игълан ителгән физик затның бурычы булу (мондый физик затка карата банкротлык турында эш кузгатылган очрактан тыш):

Россия Федерациясе Салым Кодексының 14 статьясындагы 3 пунктында һәм 15 статьясындагы 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелмәгән салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча бурычлар өлешендә;

Россия Федерациясе Салым Кодексының 14 статьясындагы 3 пунктында һәм 15 статьясындагы 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән салымнар буенча аның мирас мөлкәте хакыннан артыграк күләмдә, шул исәптән мирас Россия Федерациясе милкенә күчкән очракта да, бурыч өлешендә;

Россия Федерациясе Салым Кодексының 14 статьясындагы 3 пунктында һәм 15 статьясындагы 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән салымнар буенча аның мирас мөлкәте хакыннан артмаган күләмдә бурыч өлешендә мондый физик зат вафат булганнан соң өч ел узгач һәм салым органында мондый мөлкәтне мирас итеп алу факты турында мәгълүмат

булмаганда;».

2. Әлеге карар 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» нда бастырып чыгарырга: https://pravo.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Глава Буревестниковского сельского поселения
Новошешминского муниципального района
Республики Татарстан Ю.М. Улитин